Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLII-5**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 26 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 6 октябрендәге II-5 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне читләштерү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 370-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 6 октябрендәге II-5 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне читләштерү турындагы Нигезләмәгә (2023 елның 28 июлендәге XL-13 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.2 пунктындагы 4 пунктчасының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4) 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мондый шартнамәнең яклары тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булган башка шартлар, шулай ук үзара килешү буенча мондый шартнамәнең яклары тарафыннан билгеләнгән башка шартлар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов